**ГЛАВА
БОЛЬШЕКАБАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

Кәньяк урамы, 1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2024 елның 21 марты** **2 номер**

# БОЕРЫК

**Җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Олы Кабан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясына ярашлы рәвештә, Территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында Олы Кабан авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Кадастр номеры 16:24:160101:3825 булган, мәйданы 190 кв. м булган, ТР, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авылы, Совет урамы, 10 ж/к адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген шартлы рәвештә "гомуми файдалану территориясе» ннән «элемтә бүлегенә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә 2024 елның 28 мартында 15.00 сәгатьтә Олы Кабан мәдәният йорты бинасында ТР, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авылы, Җиңү урамы, 5 йорт адресы буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 2024 елның 27 мартына кадәр Татарстан Республикасы Лаеш районы Кече Кабан авылы, Көньяк урамы, 1 адресы буенча язма рәвештә җибәрергә.

4. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Олы Кабан
авыл җирлеге Советы рәисе** **И.Г. Шәрәфиев**